РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН

ГЛАВА
БОЛЬШЕШИНАРСКОГО
СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
САБИНСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО
РАЙОНА

ТАТАРСТАН
РЕСПУБЛИКАСЫ
САБА МУНИЦИПАЛЬ
РАЙОНЫ ОЛЫ ШЫҢАР
АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ БАШЛЫГЫ

422054, Республика Татарстан, Сабинский район,
с. Большой Шинар, ул.Кооперативная,36
тел. (84362) 41-2-11

422054. Татарстан Республикасы, Саба районы.
Олы Шыңар авылы. Кооператив урамы. 36 йорт
тел. (84362) 41-2-11

e-mail: bshin.sab@tatar.ru

ПОСТАНОВЛЕНИЕ
22.07.2024

КАРАР
№5

Саба муниципаль районы Олы Шыңар авыл
җирлеге башлыгының 11.03.2016елгы 2нче
номерлы карары белән расланган Татарстан
Республикасы Саба муниципаль районы
Олы Шыңар авыл җирлеге Советының
гражданнар мөрәҗәгатьләрен карау
һәм вазыйфаи затларның шәхси кабул итү
тәртибенә үзгәрешләр кертү турында

«Татарстан Республикасында гражданнарның мөрәҗәгатьләре турында «Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында» 09. 12.2023 елгы №124-ТРЗ Татарстан Республикасы Законына таянып, Саба районы прокуратурасының 13.07.2024 №02-08-01-2023/Прдп298 -24-20920031 протесты нигезендә

КАРАР БИРӘМ:

1. «Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Олы Шыңар авыл җирлеге башлыгының 11.03.2016 елгы 2нче номерлы карары белән расланган “Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Олы Шыңар авыл җирлеге Советының гражданнар мерәҗәгатьләрен карау һәм вазыйфаи затларның шәхси кабул итү тәртибен раслау турында» Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Олы Шыңар авыл җирлеге Советының гражданнар мөрәҗәгатьләрен карау һәм вазыйфаи затларның шәхси кабул итү тәртибен карау тәртибенә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. 7 пунктның 7.2 пунктчасында «электрон адрес» сүзләрен«федераль дәүләт мәгълүмат системасыннан файдаланганда электрон почта адресы йә шәхси кабинет адресы (уникаль идентификаторы) «дәүләт һәм муниципаль хезмәтләрнең (функцияләрнең)Бердәм порталы,» дигән сүзләре белән алыштырырга;

1.2. 7 пунктның 7.3 пунктчасында «электрон почта адресы» сүзләрен «электрон почта адресы йә Бердәм порталдагы шәхси кабинет адресы,» сүзләренә алмаштырырга;

1.3. 14 пунктның 14.9 пунктчасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Гражданнарны шәхси кабул итү өчен билгеләнгән көннәрдә һәм сәгатьләрдә органнарда чираттан тыш шәхси кабул итү хокукына I, II төркөм инвалидлар, инвалид балалар һәм мондый балаларны озата баручы затлар ия.

Гражданнарны шәхси кабул итү өчен билгеләнгән көннәрдә һәм сәгатьләрдә органнарда беренче чиратта шәхси кабул итү хокукына ия:

1) Бөек Ватан сугышы ветераннары, Россия Федерациясе Геройлары, Советлар Союзы Геройлары, Дан орденының тулы кавалерлары, Социалистик Хезмәт Геройлары, Россия Федерациясе Хезмәт Геройлары, сугышчан хәрәкәтләр ветераннары;

2) ятим балалар, ата-ана тәрбиясеннән мәхрүм калган балалар, ятим балалар һәм ата-ана тәрбиясеннән мәхрүм калган балалар исәбендәге затлар, шулай ук аларның законлы вәкилләре һәм вәкилләре, әгәр алар мондый балаларның хокукларын һәм законлы мәнфәгатьләрен тәэмин итүгә һәм яклауга бәйле мәсьәләләр буенча мөрәҗәгать итсәләр;

3) I, II теркем инвалидларның, инвалид балаларның законлы вәкилләре һәм вәкилләре, әгәр алар инвалидларның, инвалид балаларның хокукларын һәм законлы мәнфәгатьләрен тәэмин итүгә һәм яклауга бәйле мәсьәләләр буенча мөрәҗәгать итсәләр;

4) өч яшькә кадәрге балалар белән кабул итүгә килгән гражданнар.»

1.4. 18 пунктның 5 пунктчасын «күрсәтелгән электрон почта адресы буенча» сүзләрен «электрон почта адресы буенча яисә шәхси кабинет адресы буенча күрсәтелгән Бердәм порталда» сүзләре белән алмаштырырга.

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә http://pravo.tatarstan.ru адресы буенча, Саба муниципаль районының Олы Шыңар авыл җирлегенең рәсми сайтында http://saby.tatarstan.ru/shinar адресы буенча бастырып чыгарырга һәм җирлекнең мәгълүмати стендларында урнаштырырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемә алам.

Авыл җирлеге башлыгы: А.Г.Гарипов